**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Карамалы авылы № 65 «11» сентябрь 2017 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Карамалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Әлеге мәсьәлә буенча җирле референдум уздыру инициативасы белән чыгарга:
"Сез 2018 елда Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр куюны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны кертеп);
3) ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар халыкка игълан ителергә тиеш.:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:
ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы авылы, Совет ур., 49нчы йорт; ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы авылы, Яшьләр ур., юл чатында 20нче йорт, ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы авылы, Яшьләр ур., 46нчы һәм 37нче йортлар арасында; ТР, Азнакай муниципаль районы, Октябрь-Бүләк авылы, Үзәк урам, мәчет каршында; ТР, Азнакай муниципаль районы, Таллы Бүләк авылы, Үзәк урам, авыл мәдәният йорты каршында.
- Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru,
- «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис Ногманов А.Р.